РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» гыйнвар 2026 ел г. Альметьевск № 85

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 08 февралендәге 212 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасын үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 26 сентябрендәге 763 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 08 февралендәге 212 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 июлендәге 962 номерлы, 2020 елның 14 декабрендәге 1838 номерлы,

заказ № 4553-940

2021 елның 02 мартындагы 281 номерлы, 2022 елның 25 октябрендәге 2451 номерлы, 2024 елның 27 июнендәге 2199 номерлы, 2024 елның 31 октябрендәге 3539 номерлы, 2025 елның 10 июнендәге 1373 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

1 бүлекнең 4 пунктын үз көчен югалткан дип санарга.

2 бүлекнең 1 пунктындагы 1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Табл.№ 1

| № п/п | Хезмәткәрләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Идарә башлыгы | 33 345,0 |
| 2 | Оператив дежурный | 25 650,0 |

4 бүлекнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«8. Әлеге Нигезләмәдә Идарә башлыгына каралган премияләр Башкарма комитет җитәкчесе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

Идарә начальнигына, Башкарма комитет җитәкчесе кушуы буенча, район бюджетының өстәмә акчалары хисабына эш нәтиҗәләре буенча башка премияләр билгеләнергә мөмкин.

Идарә башлыгына түләүләр хисап чорының икенче яртысы өчен хезмәт хакы белән бер үк вакытта башкарыла.»;

4 бүлекнең 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Хезмәткәрләрнең хезмәт хакы аена 2 тапкыр түләнә: айның беренче яртысы өчен хезмәт хакы хисап аеның 15 числосына кадәр түләнә; айның икенче яртысы өчен хезмәт хакы хисап аеның 30 числосына кадәр түләнә»;

5 бүлекнең 3 пунктын үз көчен югалткан дип санарга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов